ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлегенең Өргәнче авылында 2022 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2022 елның «22» ноябреннән № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлегенең Өргәнче авылындагы гражданнар җыены нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Өргәнче авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 600 сум күләмендә, Россия Федерациясе Хәрби көчләренә алынучылар, аларның гаилә әгъзаларынан тыш үзара салымны кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Зирекле авыл җирлегенең Өргәнче авылында мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы» нда: (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районының
Зирекле авыл җирлеге башлыгы Җ.Г. Гайфетдинов